| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.03.2019 с.Старое Дрожжаное № 148

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру Регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексына туры китереп, Чүпрәле районы прокурорының 12.03.2019 ел № 02-08-02-2019 протестын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 09.10.2014 ел № 655 карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру Регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертәргә:

1) 3 бүлекнең 3.3 пунктында:

түбәндәге эчтәлектәге 1.1. подпунктын өстәргә:

«1.1) йортны файдалануга бирүче булып эшчәнлеге тикшерелергә тиеш зат торган социаль файдаланудагы беренче йортны социаль файдаланудагы йортлар муниципаль реестрында исәпкә алу;»;

түбәндәге эчтәлектәге 3 подпунктын өстәргә:

«3) коммуналь ресурслар (коммуналь хезмәтләр) куллану нормативларын билгеләү яки үзгәртү.»;

2) 4 бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 4.2.1. пункты белән тулыландырырга:

«4.2.1. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып, әлеге Регламентның 4.2. пунктында күрсәтелгән нигезләр белән беррәттән, муниципаль торак контроле органына, аерым алганда система аша кергән гражданнарның, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрнең, юридик затларның, мөрәҗәгатьләре һәм гаризалары, дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан алынган мәгълүмат, дәүләт торак күзәтчелеге органы, муниципаль торак контроле органы тарафыннан мәгълүмат системасы аша табылган күп квартиралы йортлардагы квартиралар, торак йортлар милекчеләренә коммуналь хезмәтләр күрсәтү, аны туктатып тору һәм чикләү кагыйдәләренең, торак милекчеләре җәмгыятен, торак, торак төзелеше яки башка махсус куллану кооперативлары төзү тәртибенә, торак милекчеләре җәмгыяте, торак, торак төзелеше яки башка махсус куллану кооперативлары уставына яки мондый җәмгыять, кооператив уставына үзгәрешләр кертү тәртибенә, күп квартиралы йортлардагы квартиралар милекчеләренең оештыру-

хокукый формасына бәйсез рәвештә күп квартиралы йорт белән идарә итүче юридик затны яки шәхси эшмәкәрне (алга таба – идарә итүче оешма) күп квартиралы йорт белән идарә итү турында килешү төзү максатында сайлап алу турындагы карарына, идарә итүче оешма белән хезмәт күрсәтү һәм (яки) күп квартиралы йорттагы гомуми милекне карап тору һәм ремонтлау турында килешү төзү турындагы карарга, Торак кодексының 164 маддәсенең 1 өлешендә күрсәтелгән затлар белән хезмәт күрсәтү һәм (яки) күп квартиралы йорттагы гомуми милекне карап тору һәм ремонтлау турында килешү төзү турындагы карарга, бу килешүләрне төзү шартларын раслау тәртибенә, күп квартиралы йорттагы гомуми милекне карап тору һәм агымдагы һәм капиталь ремонт ясау тәртибенә таләпләрнең үтәлмәү фактлары, күп квартиралы йортта перепланировка һәм (яки) бүлмәләрне яңартып кору тәртибен бозу турындагы фактлар, идарә итүче оешма тарафыннан Торак кодексының 162 маддәсенең 2 өлешендә күздә тотылган йөкләмәләрен үтәмәү фактлары, коммуналь хезмәтләр өчен гражданнардан алынган түләүләрнең чик (максималь) индексларын куллану өлкәсендәге закон бозу фактлары, коммуналь ресурслар (коммуналь хезмәтләр) куллануның билгеләнгән нормативлары нигезсез булу фактлары, коммуналь ресурслар (коммуналь хезмәтләр) куллануның билгеләнгән нормативлары составына таләпләрнең үтәлмәү фактлары, коммуналь ресурслар (коммуналь хезмәтләр) куллану нормативларын билгеләү шартларын һәм методикасын үтәмәү фактлары, күп квартиралы йорттагы гомуми милекне карап тору һәм торак мәйданны карап тору өчен түләүләрнең күләмен үзгәртү кагыйдәләрен бозу фактлары, социаль файдаланудагы торак йортларда торакны файдалануга бирүчеләр тарафыннан торак бирүчеләргә һәм андый йортлардагы торактан файдаланучыларга карата, социаль файдаланудагы торак йортларда торакны файдалануга бирү турында килешү төзү һәм аны үтәүгә карата мәҗбүри таләпләрне үтәмәү фактлары, күп квартиралы йортлар белән идарә итү буенча эшчәнлек алып баручы җирле үзидарә органнары, ресурс белән тәэмин итүче оешмалар, затлар, аерым гражданнар тарафыннан системада мәгълүмат урнаштыру тәртибенә таләпләрнең үтәлмәү фактлары тора. Муниципаль торак контроле органы (Россия Федерациясе субъектлары дәүләт органнары тарафыннан җирле үзидарәнең вәкаләтле органнарына лицензия контролен гамәлгә ашырганда тикшерү үткәрү буенча аерым дәүләти вәкаләтләр бирелгән очракта) тарафыннан планнан тыш тикшерү үткәрелү өчен нигез булып Россия Федерациясе баш дәүләт торак инспекторының планнан тыш тикшерү билгеләү турындагы Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте кушуы буенча кабул ителгән боерыгы (карары) тора. Күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш тикшерү прокуратура органнары белән килештерелмичә һәм тикшерелүче оешмага планнан тыш тикшерү турында алдан хәбәр итмичә башкарыла.».

2. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматлар Порталында урнаштырырга.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазифаларын башкаручы: И.Р. Измайлов